**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Кәркәүч авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**10 ноябрь 2025 ел** **№ 4**

**«Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Салтык-Ерыклы авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2025 елның 20 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Салтык-Ерыклы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Салтык-Ерыклы авылы, Тукай урамы, 32 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Салтык-Ерыклы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2026 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен җиһазлар белән тәэмин итү өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау;
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр);

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Кәркәүч авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Кәркәүч авыл
җирлеге башлыгы | М.Ф.Зайнутдинов